ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«СТАРОШУГУРОВСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ИСКЕ ШӨГЕР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 елның 31 октябре № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Лениногорск муниципаль районының Иске Шөгер авыл җирлеге Уставына таянып, Лениногорск муниципаль районының Иске Шөгер авыл җирлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. 2019 елның 17 ноябрендә сәгать 10.00 сәгатькә Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарылырга тиешле сорауны расларга:

2020 елда Лениногорск муниципаль районының Иске Шөгер авыл җирлеге Иске Шөгер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, I төркем инвалидларыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, күп балалы гаиләләрдән кала, 200 сум күләмендә үзара салым тапшыру һәм аларны түбәндә күрсәтелгән җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

-урам утларын карап тоту;
-зират коймасын төзекләндерү;
- Молодежная урамына белдерү тактасы урнаштыру;
-юллар ремонтлау һәм кардан чистарту.

« ӘЙЕ» «ЮК».

2. Әлеге карарны Иске Шөгер авыл җирлеге Иске Шөгер авылында урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://Ieninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы урынбасары А.А.Гыймаев